КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 август г.Казань № 707

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе уставын раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2019 ел, 27 февраль, 129 нчы карары белән расланган «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе уставына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе уставын раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үз көчен югалткан дип тану хакында» 2019 ел, 27 февраль, 129 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 10 октябрь, 901 нче; 2021 ел, 22 июль, 644 нче; 2022 ел, 5 декабрь, 1284 нче; 2023 ел, 6 октябрь, 1251 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктның икенче абзацында «, а/я 114» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.4.13 пунктның 2.4 пунктчасында:

беренче абзацта:

«башка йөк автомобильләре,» сүзләреннән соң «азсыешлы суднолар,» сүзләрен өстәргә;

«һәм башка машиналар» сүзләрен «һәм башка үзйөрешле машиналар» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта:

«башка йөк автомобильләре,» сүзләреннән соң «азсыешлы суднолар,» сүзләрен өстәргә;

«һәм башка машиналар» сүзләрен «һәм башка үзйөрешле машиналар» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин